| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 6 июне № 15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 37 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында ( 2017 елның 30 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 37 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым Кодексының 361.1 маддәсенең 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 37 номерлы «Җир салымы турында» карарына (2017 елның 30 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 37 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктта 2 һәм 3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар салым органында юк икән, шул исәптән салым түләүче тарафыннан салым ташламасы бирү турында салым түләүченең гаризасында күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслый торган белешмәләрне салым ташламасына салым түләүченең, әлеге мәгълүматлар булган органнар һәм башка затларның соратып ала.

Салым органыннан салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслый торган мәгълүматларны тапшыру турында салым органы соратып алган башка зат аны алган көннән җиде көн эчендә яисә шул ук вакытта салым органына сорауның үтәлмәве сәбәпләре турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Сугышлы авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Ф.К.Янгирова